**ГЛАВА**
**Исенбаевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Исәнбай авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

13.10.2020 Исәнбай авылы № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 27 октябрендә 10 сәг 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2020 елның 27 октябрендә 11 сәг 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын 2020 елның 27 октябрендә 12 сәг 00 минутка билгеләргә.
4. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:

-1 этап: Исәнбай авылының Совет ур., Хезмәт ур., Елга ур. яшәүчеләре.

-2 этап: Исәнбай авылының Октябрьская, Школьная, Береговая ур. яшәүчеләре.

-3 этап: Исәнбай авылының Кирпичная, Ленин, Яшьләр ур. яшәүчеләре.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчалары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Исәнбай авылы территориясендә су насослары, колонкалар, сантехник материаллар, су үткәргечен алыштыру өчен полиэтилен торбалар һәм краннар сатып алу;

2. Лампаларга, дроссельләргә, фонарьларга хезмәт күрсәтү, ремонт ясау һәм алыштыру, Исәнбай авылында урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу;

3. Исәнбай авылы урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу);

4. Бима елгасы аша Исәнбай авылы күперен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу һәм башкарылган эш өчен түләү);

5. Исәнбай авылының Совет, Октябрьская урамнарын ремонтлау өчен вак таш сатып алу;

6. МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен өстәмә асылма җиһазлар сатып алу (төягеч, ротор чапкычы);

7. Исәнбай авылында чишмәләр территориясен төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Исәнбай авылы, Совет урамы, 79 йорт адресы буенча, авыл мәдәният йорты каршындагы мәйданчыкта үткәрергә.

7. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф. Сираев

Совет Исенбаевского сельского поселения
Исенбай авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002653